ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

02.08.2018 г. Казань № 97-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 11.01.2017 № 004-од боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарны үтәүне тикшереп тору буенча дәүләт вазыйфасын башкару буенча административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 11.01.2017 № 004-од боерыгы белән расланган административ регламентына (Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 29.08.2017 № 111-од боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

(икенче абзац 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керә)

2.16 пунктының 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан тиешле өлкәдә федераль башкарма хакимият органы» сүзләрен «тиешле өлкәдә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

(өченче – ундүртенче абзацлар 2018 елның 19 августында үз көченә керә)

5.22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.22. Юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеген планлы документар тикшерү уздыру турында, аның нәтиҗәләре турында, ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү чаралары турында мәгълүмат тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару һәм формалаштыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

5.33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.33. Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлегенә планлы күчмә тикшерү турында, аның нәтиҗәләре турында, ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү чаралары турында мәгълүмат тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару һәм формалаштыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

5.44 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.44. Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлегенә планнан тыш тикшерү турында, аның нәтиҗәләре турында, ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү чаралары турында мәгълүмат тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару һәм формалаштыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

5.56 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.56. Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлегенә планнан тыш күчмә тикшерү турында, аның нәтиҗәләре турында, ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү чаралары турында мәгълүмат тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару һәм формалаштыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш.»;

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Язма шикаятьтә юридик затның атамасы күрсәтелмәгән (гариза бирүче юридик зат булса), шикаятьне җибәрүче гариза бирүченең фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, шикаятькә җавап бирелми.

Шикаятьтә оятсыз йә мәсхәрәләүче гыйбарәләр булу, вазыйфаи зат, аның гаилә әгъзалары гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булган очракта, шикаять анда куелган мәсьәләләр асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Шикаять җибәргән гариза бирүчегә бу очракта әлеге хокуктан явыз ниятләрдә файдалану мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Язма шикаять тексты укылмаслык булган очракта, шикаять җавапсыз калдырыла һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелә, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән җиде көн эчендә, әгәр гариза бирүченең фамилиясе һәм почта адресы укылырлык булса, гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Язма шикаять текстында шикаять асылын билгеләү мөмкин булмаган очракта, шикаятькә җавап бирелми һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелә, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән җиде көн эчендә, әгәр гариза бирүченең фамилиясе һәм почта адресы укылырлык булса, гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Шикаятьтә элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә асылы буенча гариза бирүчегә берничә мәртәбә шушы ук сорау буенча язма җаваплар җибәрелгән очракта, һәм бу чакта шикаятьтә Дәүләт комитеты рәисе, вазыйфаи зат һәм Дәүләт комитетының шуңа вәкаләтле заты шикаять белән чираттагы мөрәҗәгать итүнең нигезсезлеге һәм язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы, бу чакта әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр Дәүләт комитетына җибәрелгән булу шарт. Шушы карар турында шикаять җибәргән гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Дәүләт комитетына яисә Дәүләт комитеты вазыйфаи затына язма шикаятьтә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы № 59-ФЗ Федераль законның 10 статьясының 4 өлеше нигезендә җавап Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган очракта, шикаять җибәргән гариза бирүчегә шикаять теркәлгән көннән җиде көн эчендә шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган Дәүләт комитетының рәсми сайтының электрон адресы хәбәр ителә, бу чакта суд карарына шикаять белдерелгән шикаять гариза бирүчегә кире кайтарылмый.

Шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш, әгәр шушы шикаятьтә әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук хокукка каршы гамәл әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса.

Суд карарына карата белдерелгән шикаять, шушы суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, теркәлгәннән соң җиде көн эчендә гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә куелган сорауның асылы буенча җавап бирү дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган бүтән серне чишмичә мөмкин булмаган очракта, шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә анда куелган сорауга асылы буенча җавап бирү әлеге белешмәләрне чишү рөхсәт ителмәүгә бәйле рәвештә мөмкин булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә куелган сорауларга асылы буенча җавап бирелмәү сәбәпләре киләчәктә бетерелгән очракта, гариза бирүче шикаятьне яңадан Дәүләт комитетына яисә аның вазыйфаи затына җибәрергә хокуклы.».

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, моңа әлеге боерыкның 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче 1 пунктындагы икенче абзацы, әлеге боерыкның 2018 елның 19 августыннан үз көченә керүче 1 пунктының өченче – ундүртенче абзацлары керми.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис Г.З. Габдрахманова